# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Исәнгол торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2025 елның 18 ноябре** **№ 6**

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге Исәнгол торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге Исәнгол торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 һәм 2 төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарын, күп балалы гаиләләрне, көндезге бүлектә укучы студентларны, 90 яшь һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге гражданнарны, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнарны, СВО зонасында хезмәт итүче гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларын искәрмә итәргә).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Исәнгол торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (яктылык җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Наратлы -Кичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль
Наратлы-Кичү авыл җирлеге башлыгы Вәлиев И.М.